**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **11.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Сарлы авыл җирлеге составына керүче
Сарлы авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Сарлы авылында юлларны кардан чистарту;
- Сарлы авылында «Сабантуй» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү;
- Сарлы авылында янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, янгын сүндерү автомобиле йөртүченең хезмәт хакы;
- Сарлы авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге Башлыгы М.Р.Шәрипов